**Чистай муниципаль районы**
**Татар Ялтаны авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

**2021 елның 29 ноябре** **№ 16/1**

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Татар Ялтаны авыл җирлеге
биләмәләреннән файдалану һәм
төзелеш алып бару кагыйдәләренә
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге Советының 2014 елның 5 июлендәге 8/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турындагы мәгълүматны тыңлаганнан һәм фикер алышканнан соң, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре буенча комиссиянең 2021 елның 26 октябрендәге 5 номерлы бәяләмәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Ялтаны авыл җирлеге Советы

*КАРАР БИРӘ:*

1. «Махсус билгеләнештәге яшелләндерү зонасы» СН2 территориаль зонасы чиген үзгәртү һәм кадастр номеры 16:42:120201:431 булган, 39000 кв.м. мәйданлы, Татарстан Республикасы, Чистай муниципаль районы, Татар Ялтаны авыл җирлеге, Изгар авылы адресы буенча урнашкан җир кишәрлеге территориясен «Авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге объектлар зонасы» (СХ1) төзелеш зонасына кертү өлешендә, Чистай муниципаль районы «Татар Ялтаны авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җир биләмәләреннән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре территориясен шәһәр төзелеше зоналаштыру картасына үзгәрешләр кертергә (1 нче кушымта).
2. Әлеге карарны җирлек халкы күпләп җыела торган урыннарда игълан итәргә һәм Чистай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Татар Ялтаны авыл җирлеге
башлыгы Гарифуллин Р.Р.